**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «9» декабреннән № 4-25

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисенә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2022 елның 29 декабрендәге 30-239 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясындагы 4 пункты, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, депутатларга хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, муниципаль норматив хокукый базаны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2022 елның 29 декабрендәге 30-239 номерлы карары (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 35-282 номерлы, 2024 елның 23 маендагы 46-345 номерлы, 2024 елның 11 июлендәге 47-355 номерлы, 2024 елның 23 октябрендәге 49-375 номелы, 2025 елның 17 апрелендәге 53-416 номерлы карарлары редакциясендә) (алга таба-Карар) белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисенә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлештә «15 389» санын «16 928» санына алмаштырырга;

1.2. Карарның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгына, Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасарына, Яңа Чишмә муниципаль районының Контроль-хисап Палатасы рәисенә ай саен акчалата түләү билгеләргә:

| Вазифа атамасы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 төркем |
| Муниципаль район Башлыгы | 44 814 |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 40 334 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 40 334 |

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында»: https://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский